**Рус телендә гомуми урта белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендә белем алучы 10 нчы сыйныф укучыларына татар әдәбиятыннан муниципаль тур өчен олимпиада сораулары**

**Хөрмәтле олимпиадада катнашучы!** Сезгә олимпиаданың җиде биремен эшләргә кирәк булачак. Биремнәрне үтәү вакыты – 180 минут. Биремнәр шушы бланкларда эшләнә.
Максималь балл – **45**. Уңышлар!

**1. Кайсы иҗат методы турында сүз баруын языгыз. (2 балл)**

- ул җәмгыятьне үзгәртеп коруның төп чарасы итеп кешеләрнең аңын үстерү, аларны гыйлемле, һөнәрле һәм югары әхлаклы итүне күрә;
- геройларны уңай һәм тискәрегә кискен аерып бирә;
- геройлар гамәлләренең, язмышларының гаилә тәрбиясенә һәм иҗтимагый мохиткә бәйле булуын билгели.

___________________________________________________________

**2. Татар әдәбиятының чишмә башы булып саналган әсәрләр авторлары рәтен күрсәтегез. (1 балл)**

а) Әхмәд Йүгнәки, Мәүлә Колый, Әхмәд Ясәви.

ә) Әхмәд Йүгнәки, Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакырганый.

б) Әхмәд Йүгнәки, Йосыф Баласагунлы, Кол Шәриф.

___________________________________________________________

___________________________________________________________

**3. Сорауларга җавап бирегез.**



**1) Портреттагы әдипнең исемен языгыз. (1 балл)**

__________________________________________

**2) Ул кайда туган? Дөрес җавапны билгеләгез. (1 балл)**

а) Казан губернасының Чистай өязендәге Яуширмә авылы

ә) Башкортстанның Җилем-Каран авылы

б) Оренбург губернасы Акман (Ибрай) авылы

в) Казан шәһәренең Яңа Бистәсе

_______________________________________________

**3. Әлеге әдип турында дөреслеккә туры килмәгән фактны билгеләгез. (1 балл)**

а) Бу әдипнең иҗатын ике чорга бүлеп өйрәнү кабул ителгән: Җаек чоры һәм Казан чоры.

ә) Ул “Таң вакыты” шигыренең авторы.

б) Аны шагыйрь Дәрдмәнд белән туганлык җепләре бәйли.

в) Ул татар әдәбиятына бунтарь рухлы романтик герой алып килә.

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

**4. Хисам Кятиб кайсы чор әдәбияты вәкиле булуын билгеләгез. (1 балл)**

а) Борынгы чор татар әдәбияты.

ә) Алтын Урда чоры әдәбияты.

б) Казан ханлыгы чоры әдәбияты.

в) Торгынлык чоры әдәбияты (XVI гасырның II яртысы – XVIII гасыр).

_____________________________________________________________

**5. Бирелгән сүзләр рәте ярдәмендә әсәрләрнең исемен, авторын һәм жанрын билгеләгез. (9 балл)**

а) Пәке, йола, шәҗәрә, миләш агачы, Гөлйөзем әби, талак, ике каен.

ә) а) Мәгарә, кимия, симия, ихфа, Мисыр, хәлвә, патша кызы, казый.

б) Хат, Җил, Ай, наборщик, комсомолка, ана, бала, ирекле сөю.

**6. Повестьтан өзекне укыгыз.**

...Шулай итеп, көннәрдән бер көнне мин төяндем дә пароходка төшеп киттем. Киң Идел мине үзенең ягымлы кочагына алгач, үземне бөтенләй исерек кеше шикелле хис иттем. Шәһәрдә торганда, рухымны басып торган авырлык кинәт әллә кая очкан, югалган иде. Минем бу вакыттагы халәти рухиямне бары яңа авырудан терелеп, беренче мәртәбә дөньяга чыккан кешенеке белән генә чагыштырырга мөмкин. Беләсезме, андый вакытта кешегә бөтен дөнья яңа булып күренә. Гүяки ул яңа гына туган яисә үлеп яңадан терелгән. Элек игътибар да итмәгән юк кына нәрсәләр дә аңар әллә ничек сөйкемле булып күренәләр; иң гади агачны, койма буенда үскән яшел чирәмне, җирдә яткан ташны, кояш астында үзенең пәрәвезен корып ята торган үрмәкүчне күрү дә аны балалар шикелле сөендерә. Мин бу тойгыны ни дип атарга да белмим инде. Минемчә, аны «тереклек шатлыгы» дип атарга яисә кинәт әллә нинди илһам буенча тормышның мәгънәсен аңлау диярга мөмкин.

Ни булса да, мин шат идем, мин бәхетле идем. Идел үзенең тулган, яңа гына яшәреп килә торган ярларында тын гына, мәһабәт кенә ага, мин бер дә уйсыз-нисез генә пароходның борынында утырам, бер ялтыраган киң Идел өстенә, бер зәңгәр һавага күземне салам. Язгы су исе килеп торган Идел җиле минем битемә бәрелә, җиңнәремнән кереп, беләкләремне кытыклый. Мин утырам да җүләр кеше шикелле үз-үземә уйлыйм: «Кара син аны, нинди матурлыклар бар икән дөньяда!» — дим.

**Өзек буенча сорауларга җавап бирегез.**

**а) Әсәрнең исеме. (1 балл)** ______________________________

**ә) Әсәрнең авторы. (1 балл)** _____________________________

**б) Өзектә әдәби геройның кая баруы тасвирлана? (1 балл)**

**Герой моңа бәйле нинди хисләр кичерә? (2 балл)**

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

**в) Өзектән**

- **метафорага мисаллар табып языгыз (2 балл)**

____________________________________________________________

____________________________________________________________

- **чагыштыруга мисал китерегез (4 балл)**

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

- **эпитетка мисаллар табып языгыз. (3 балл)**

____________________________________________________________

____________________________________________________________

___________________________________________________________

**7. Үзегез яратып укыган әдәби әсәрне исемен күрсәтмичә, ләкин аны таныrлык итеп характерлап языгыз. Ахырдан әсәрнең исемен, авторын күрсәтегез. Күләме 10-12 җөмлә. (15 балл)**

____________________________________________________________

____________________________________________________________